| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО БИОЛОГИЧЕСКИМ РЕСУРСАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ БИОЛОГИК РЕСУРСЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**Приказ** **Боерык**

16.05.2018 г. г. Казань № 126-од

Татарстан Республикасы территориясендә аучылык һәм биологик су ресурсларына кертелмәгән, хайваннар дөньясы объектларын тотуга рөхсәтнамәләр бирү буенча дәүләт хезмәтен күрсәтүнең Административ регламентын раслау турында

2010 елның 22 апреленнән 293 номерлы "Татарстан Республикасы территориясендә аучылык һәм биологик су ресурсларына кертелмәгән, хайваннар дөньясы объектларын тоту тәртибен раслау турында" ,2010 елның 2 ноябреннән 880 номерлы "Татарстан Республикасының башкарма хакимият әгъзаларының хезмәт күрсәтүләре буенча адмистратив регламентларны эшләү һәм раслау Тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында "гы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының карарларын тормышка ашыру һәм физик һәм юридик затларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен гамәлгә ашыруны тәэмин итү, Татарстан республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетының структур бүлекчәләре белән дәүләт хезмәте күрсәтү буенча эшчәнлекне регламентлаштыру һәм стандартлаштыру максаты белән **боерам:**

1. Татарстан республикасының хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм файдалану Идарәсенең 2016 елның 28 июленнән 158-од номерлы "Аучылык һәм биологик су байлыкларына кертелмәгән, хайваннар дөньясы объектларын тотуга рөхсәтнамәләр бирү буенча дәүләт хезмәтен күрсәтүнең Административ регламентын раслау турында"гы боерыкны көчен югалткан дип санарга.
2. Кушылып бирелгән Татарстан Республикасы территориясендә аучылык һәм биологик су ресурсларына кертелмәгән, хайваннар дөньясы объектларын

тотуга рөхсәтнамәләр бирү буенча дәүләт хезмәтен күрсәтүнең Административ регламентын расларга.

3. Рәис урынбасарларына, структур бүлекчәләр җитәкчеләренә,дәүләт хезмәтен турыдан-туры күрсәтүче затларга, Регламентның кагыйдәләрен тотуны һәм аның белән каралган туры килүче документларны алып баруны тәэмин итәргә.

4. Хокукый эш буенча алдынгы киңәшче В.В. Фугинга бу боерыкны дәүләт теркәвенә һәм Татарстан Республикасының Рәсми хокукый мәгълүматлар порталында рәсми бастыру өчен Татарстан Республикасының Юстиция Министрлыгына юнәлтергә.

5. Боерыкның үтәлүе артыннан тикшерүне рәис урынбасары Р.Г. Шәрәфетдиновка тапшырырга.

Рәис вазыйфаларын үтәүче Ю.Б. Матвеев

16.05.2018 елдан 126-о номерлы
Татарстан республикасының
Биологик ресурслар буенча дәүләт
комитеты Боерыгы белән расланды

**Татарстан Республикасы территориясендә аучылык һәм биологик су ресурсларына кертелмәгән , хайваннар дөньясы объектларын тотуга рөхсәтнамәләр бирү буенча дәүләт хезмәтен күрсәтүнең Административ регламенты**

## 1. Гомуми кагыйдәләр

1.1. Татарстан Республикасы территориясендә аучылык һәм биологик су ресурсларына кертелмәгән, хайваннар дөньясы объектларын тотуга рөхсәтнамәләр бирү буенча дәүләт хезмәтен күрсәтүнең Административ регламенты, дәүләт хезмәтен күрсәтүнең стандартын һәм тәртибен .

1.2. Дәүләт хезмәтен алучылар: юридик һәм физик затлар (алга таба – гариза бирүчеләр).

1.3. Дәүләт хезмәте Татарстан республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты белән күрсәтелә (алга таба - Комитет).

1.3.1. Комитетның урнашу урыны: Казан, Кәрим Тинчурин урамы, 29 йорт.

Комитетның эш вакыты: шимбә һәм якшәмбедән кала, көн саен, дүшәмбе – пәнҗешәмбе 9.00-18.00, җомга 9.00-16.45. Төшке аш 13.00-13.45.

График приема заявлений: г. Казань, ул. Карима Тинчурина, д. 29.

Иҗтимагый транспорт белән “Татарстан” тукталышына кадәр :

автобуслар № 1, 31, 53, 54, 6, 71;

троллейбуслар № 3, 5;

трамвай № 7;

«Ахтямов» тукталышына кадәр:

автобуслар № 23,5, 56, 68, 71, 72.

Бинага керү шәхесне раслый торган документ буенча.

1.3.2. Дәүләт хезмәтен күрсәтү тәртибе һәм үтәлеше турында мәгълүматны белдерү Хайваннар дөньясын күзәтү бүлеге белән алып барыла ( алга таба – Бүлек). Телефон: (843) 211-70-78.

Информирование о порядке предоставления государственной услуги и ходе

1.3.3. ТР Биоресурслар буенча Дәүләт Комитетының мәгълүмати-телекомммуникатив “Интернет” челтәрендә, рәсми сайт адресы

http://www.ojm.tatar.ru.( алга таба – Комитетның рәсми сайты һәм Интернет челтәре)

1.3.4. Дәүләт хезмәте турында мәгълүмат түбәндәге чыганаклардан алынырга мөмкин:

1) “Интернет” челтәре аша Комитетның рәсми сайтында (http://ojm.tatarstan.ru/rus;);

2) Татарстан Республикасының Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан (http://uslugi.tatar.ru/);

3) Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында(http://www.gosuslugi.ru);

4) ТР Биоресурслар буенча Дәүләт Комитетына телдән мөрәҗәгать итеп (телефон аша (843)211-70-78 яки шәхси (102 кабинет));

5) ТР Биоресурслар буенча Дәүләт Комитетына язмача мөрәҗәгать итеп (шул санда ojm@tatar.ru рәсми электрон почтага җибәрелгән электрон документ рәвешендә).

6) ТР Биоресурслар буенча Дәүләт Комитеты биналарында дәүләт хезмәте турында турыдан-туры күреп һәм текстлы мәгълүмат булган, дәүләт хезмәте турында мәгълүмати стендлар ярдәмендә.

1.3.5. Дәүләт үхезмәтен күрсәтү сораулары буенча мәгълүмат, Бүлек белгечләре белән Комитетның рәсми сайтында һәм Коминет бинасында мәгълүмати стендларда урнаштырыла.

Мәгълүмати стендларда урнаштырылган мәгълүмат, дәүләт хезмәте турында, бу Регламентның 1.3.1, 2.1, 2.3, 2.4, 2.5, 2.8, 2.10, 2.11, 5.1 пунктларында бирелгән мәгълүматны үз эченә ала.

1.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтү түбәндәге актлар белән җайга салына:

Россия Федерациясенең Салымнар Кодексы белән (алга таба - РФ СК) ( Россия Федерациясе кануннары җыентыгы, 2000, №32, 3340 маддә, кертелгән үзгәрешләрне истә тотып);

24.04.1995 ел. № 52-ФЗ “ Хайваннар дөньясы турында”гы Федераль канун белән; (алга таба – № 52-ФЗ Федераль канун) (РФ кануннар җыентыгы, 24.04.1995, № 17, 1462 маддә, кертелгән үзгәрешләрне истә тотып);

27.07.2010 ел. № 210-ФЗ “Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында”гы Федераль канун белән (Россия Федерациясенең кануннар җыентыгы, 02.08.2010, №31, 4179 маддә, кертелгән үзгәрешләрне истә тотып);

06.04.2011 ел. № 63-ФЗ “Электрон имза турында”гы Федераль канун белән (

алга таба-№ 63-ФЗ Федераль канун) (Россия Федерациясенең кануннар җыентыгы, 2011, № 15, 2036 маддә, кертелгән үзгәрешләрне истә тотып);

07.05.2012 ел. 601 номерлы "Дәүләт идарәсе системасын камилләштерүнең төп юнәлешләре турында"гы Россия Федерациясе Президенты Боерыгы (алга таба – 601 номерлы РФ Президенты Боерыгы) (Россия Федерациясенең кануннар җыентыгы, 2012, № 19, 2338маддә);

10.01.2002 ел. № 7-ФЗ " Тирә-як мохитне саклау турында"гы Федераль канун белән (Россия Федерациясенең кануннар җыентыгы, 2002, № 12, 133 маддә, кертелгән үзгәрешләрне истә тотып);

Татарстан Республикасының Экология Кодексы белән (алга таба – ТР ЭК) (Татарстанның Дәүләт Киңәшмәсе Хәбәрләре, 2009, №1, 5 маддә, кертелгән үзгәрешләрне истә тотып);

06.02.2001 елдан №57 "Татарстан Республикасының Кызыл китабына кертелгән, сирәк һәм бетү куркынычы яный торган төр хайваннарны һәм үсемлекләрне куллануга рөхсәтнамә бирү тәртибе турында" гы Татарстан Республикасының Министрлар Кабинеты боерыгы белән расланган, Татарстан Республикасының Кызыл китабына кертелгән, сирәк һәм бетү куркынычы яный торган төр хайваннарны һәм үсемлекләрне куллануга рөхсәтнамә бирү тәртибе белән ( алга таба- ТР МК №57 боерыгы белән расланган Тәртип) ("Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының карарлары һәм боерыклары һәм башкарма хакимият республика әгъзаларының норматив актлары җыелмасы" журнал, 2012, №64, 2464 маддә, кертелгән үзгәрешләрне истә тотып);

31.08.2004 елдан 395 номерлы "Татарстан Республикасы бюджетыннан ассигнование ала торган бюджет оешмаларының һәм башка оешмаларның эшмәкәрлек эшчәнлеге турында"гы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының карары белән (алга таба- № 395 карар) (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының боерыклар һәм карарлар һәм башкарма хакимиятнең республика әгъзаларының норматив актлары җыентыгы, 08.09.2004, № 34, 0685маддә, кертелгән үзгәрешләрне истә тотып);

22.04.2010 елдан 293 номерлы "Татарстан Республикасы территориясендә аучылык һәм биологик су байлыкларына кертелмәгән, хайваннар дөньясы объектларын тоту тәртибен раслау турында"гы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының карары белән ( алга таба – Тәртип)( ТРМК һәм башкарма хакимиятнең республика әгъзаларының карарлар һәм боерыклар җыентыгы, 2010 ел, №22, кертелгән үзгәрешләрне истә тотып);

02.11.2010 елдан "Татарстан Республикасының башкарма хакимият әгъзаларының хезмәт күрсәтүләре буенча адмистратив регламентларны эшләү һәм раслау Тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгешләр кертү турында "гы 880 номерлы

Татарстан Республикасы министрлар Кабинетының карары (алга таба –ТРМК 880 номерлы карары)(Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының карарлар һәм күрсәтмәләр һәм республика башкарма хакимият әгъзаларының норматив актлары җыентыгы, 08.12.2010, № 46,2144 маддә, кертелгән үзгәрешләр белән);

15.12.2017елдан 996 номерлы “Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты турында Кагыйдәнамәне раслау турында”гы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының карары ( алга таба – Комитет турында Кагыйдәнамә) (Татарстан Республикасының кануннар җыентыгы, 2017, № 95, 3544 маддә, кертелгән үзгәрешләрне истә тотып).

1.5. Бу регламентта киләсе атамалар һәм билгеләмәләр кулланыла:

**хайваннар дөньясы** – Россия Федерациясе территориясендә даими рәвештә яки вакытлыча яши торган һәм табигый азатлыкта булган, ә шулай ук Россия Федерациясенең континенталь шельф табигый байлыкларына һәм икътисади зонасына карый торган барлык төр кыргый хайваннарның тере организмнар барлыгы.

**хайваннар дөньясы объекты** - хайваннар чыгышына караган организм ( кыргый хайван);

**хайваннар дөньясы объектларын куллану** - хайваннар дөньясы объектларын тоту, өйрәнү, яки кешенең материаль яисә рухи ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен, күрсәтелгән объектларны яшәү тирәлекләреннән алып яки алмыйча, алардан башка төрле итеп файда алу.

**рөхсәтнамә** - урынын һәм вакытын күрсәтеп, билгеле төр хайваннар дөньясы объектларын кулланырга хокук бирә торган, исемле документ.

**ясалма яшәү тирәлеге** –кыргый хайванның яшәешен тәэмин итү өчен кирәкле һәм аның гомеренә һәм сәламәтлегенә куела торган һәвефсезлек таләпләренә, санэпидем- һәм зоологик таләпләргә , ә шулай ук кешенең гомеренә һәм сәламәтлегенә куела торган һәвефсезлек таләпләренә җавап бирә торган, табигый яшәү тирәлегенә якынлашкан ясалма шартлар.

**ярымирекле шартлар** – Татарстан Республикасының табигый объектларында, аларны асрау өчен билгеләнгән чикләрдә һәм кыргый хайваннарның яшәешен өлешчә кеше тәэмин итә торган, хайваннарның күченүен чикли торган система.

**техник хата** – алар нигезендә мәгълүмат кертелгән документлардагы мәгълүмат белән,кертелгән документтагы(дәүләт хезмәте нәтиҗәсе) мәгълүматның туры килмәвенә китергән, дәүләт хезмәте күрсәтүче әгъза белән җибәрелгән хата( хәреф хатасы, грамматик яки арифметик хата).

**дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урыны** – муниципаль районнарның авылларында гаризачыларга мәгълүмат бирү, документларны кабул итү һәм бирү тәрәзәсе.

Бу Регламентта дәүләт хезмәтен күрсәтү турында гариза астында ( алга таба – гариза) дәүләт хезмәтен күрсәтү турында мөрәҗәгать күз алдында тотыла (210-ФЗ номерлы Федераль канун 2 нче маддә 1 пункт). Тәкъдим ителгән гариза формасы бу регламентның 1нче кушымтасында бирелә.

## 2. Стандарт предоставления государственной услуги

| Дәүләт хезмәтен күрсәтү стандартына куела торган таләпнең исеме | Стандартка куела торган таләпнең эчтәлеге | Таләпне яки дәүләт хезмәтен билгели торган норматив акт |
|---|---|---|
| 2.1.Дәүләт хезмәтенең атамасы | Татарстан Республикасы территориясендә аучылык һәм биологик су байлыкларына кертелмәгән, хайваннар дөньясы объектларын тотуга рөхсәтнамә бирү | 52-ФЗ номерлы Федераль канун 43 маддә |
| 2.2. Дәүләт хезмәтен күрсәтүче әгъзаның атамасы | Татарстан республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты | 996 нчы карар |
| 2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсенең тасвирламасы | 1. Татарстан Республикасы территориясендә аучылык һәм биологик су байлыкларына кертелмәгән, хайваннар дөньясы объектларын тотуга рөхсәтнамә;<br>2. Татарстан Республикасы территориясендә аучылык һәм биологик су байлыкларына кертелмәгән, хайваннар дөньясы объектларын тотуга рөхсәтнамәне бирмәү турында хат. | Комитет турында Кагыйдәнамә;<br>52-ФЗ номерлы Федераль канун 43 маддә |
| 2.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтү вакыты, шул | Гаризаны теркәгәннән соң 10 көн эчендә. | |

| | | |
|---|---|---|
| санда дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнаша торган, оешмаларга мөрәҗәгать итү кирәклеген, РФ кануннары белән каралган мөмкинлек булган очракта, дәүләт хезмәтен күрсәтүне туктатып тору вакытын истә тотып | Дәүләт хезмәтен күрсәтү вакытын туктатып тору каралмаган. | |
| 2.5. Дәүләт хезмәте, шулай ук мөрәҗәгать итүчегә күрсәтелергә тиешле дәүләт хезмәтләрен күрсәтү өчен зарури һәм мәҗбүри булган хезмәтләрне күрсәтү өчен<br><br>канун яки башка норматив-хокукый актлар нигезендә кирәкле документларның тулы исемлеге, аларны алу ысуллары, шул санда электрон рәвештә, күрсәтү тәртибе. | 1. Гариза (2 нче кушымта);<br>2. Юридик затлар өчен – оештыру документларының күчермәсе, физик затлар өчен – паспорт күчермәсе;<br>3. Тоту һәм үрчетү максаты белән хайваннар дөньясы объектларын тотканда – хайваннар дөньясы объектларын ярым ирекле шартларда һәм ясалма тирәлектә тотуга һәм үрчетүгә рөхсәтнамә күчермәсе.<br>Дәүләт хезмәтен алыр өчен гариза бланкын гариза бирүче шәхси Комитеттан алырга мөмкин.<br><br>Бланкның электрон формасы Комитетның рәсми сайтында урнаштырылган.<br><br>Гариза һәм аңа кушылган документлар, гариза бирүче белән, кәгазьдә киләсе ысуллар белән тапшырыла алалар:<br><br>шәхси (ышанычнамә нигезендә гариза бирүче исеменнән эш итүче зат белән);<br><br>почта аша, алу турында белдерү кәгазе булган | Тәртип п.2.6 |

| | | |
|---|---|---|
| | заказлы хат белән.<br><br>Документлар, гариза бирүче белән, электрон имза белән расланып, шулай ук электрон рәвештә, “Интернет” челтәре мәгълүмат ресурслары яки Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша юнәлтелергә мөмкин.<br><br>Шулай ук гариза һәм аңа кушылган документлар, гариза бирүче белән, интернет челтәре аша яки Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша, исемен, почта адресын( электрон адресны), гариза бирүченең телефон номеры,физик затның исем, фамилиясен, атасының исемен, тору урынын күрсәтеп, электрон имза белән раслап, электрон рәвештә тапшырыла ала.<br><br>Әгәр дә гариза бирүче хокуклы вәкил сыйфатында яки дәүләт хезмәтен алырга вәкаләтле зат сыйфатында килгән очракта, гариза бирүчегә гаризага, вәкаләтләрне раслый торган документны да теркәргә кирәк.<br><br>Шәхси мөрәҗәгать иткәндә, шулай ук вәкилнең шәхесен раслый торган документ күрсәтелергә тиеш. | |

| | | |
|---|---|---|
| 2.6. Дәүләт әгъзалары, җирле үзидарә әгъзалары һәм башка оешмалар карамагындагы, дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен норматив-хокукый актлар нигезендә, гариза бирүче тапшырырга хокуклы булган кирәкле документларның тулы исемлеге, ә шулай ук гаризачылар белән аларны алу ысуллары, шул санда электрон рәвештә; кирәкле документлар аларның кулланыуында булган дәүләт әгъзалары, җирле үзидарә әгъзалары һәм башка оешмалар. | Электрон идарәара бәйләнеш системасы буенча алыналар:<br>1. Хайваннар дөньясы объектларын тотуга рөхсәтнамә бирү өчен дәүләт пошлинасын түләү турында билгене раслау (Татарстан Республикасы буенча Федераль Казначейлык идарәсеннән) ;<br>2. Юридик затларның Бердәм дәүләт реестрыннан яки шәхси эшмәкәрләрнең Бердәм дәүләт реестрыннан өземтә (Татарстан Республикасы буенча Федераль салымнар хезмәте Идарәсеннән).<br>Комитет, гаризада күрсәтелгән хайваннар дөньясы объектларын тоту мөмкинлеге һәм максатчанлыгы турында нәтиҗә һәм рекомендацияләр алу өчен, гаризаны туры килүче фәнни яки башка вәкаләтле оешмага җибәрергә хокуклы.<br>Гариза бирүче өстә күрсәтелгән документларны үзлегеннән тапшырырга хокуклы.<br>Гариза бирүчедән дәүләт әгъзалары, җирле үзидарә әгъзалары һәм башка оешмалар кулланыуында булган, өстә күрсәтелгән документларны таләп итәргә тыела.<br>Гариза бирүче белән, өстә күрсәтелгән документларны тапшырмау, дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен документларны кабул итүдән кире кагуга нигез булып килми. | РФ СК 333.33 маддә п.п. 96 п. 1<br><br>Тәртипнең 2.6.1 пункты |

| | | |
|---|---|---|
| 2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен таләп ителгән һәм дәүләт хезмәтен күрсәтүче башкарма әгъза тарафыннан тормышка ашырыла торган норматив-хокукый актларда каралган очракларда килештерү зарури булган дәүләт хакимияте әгъзалары һәм аларның структур бүлекчәләре исемлеге | Дәүләт хезмәтен килештерү таләп ителми. | |
| 2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тартуга нигезләрнең тулы исемлеге | Документларны кабул итмәскә нигезләмәләр юк. | |
| 2.9. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яки дәүләт хезмәтен<br><br>күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр:<br>1. Хайваннар дөньясы объектларын тотуга гариза язылган территориядә, барлык хайваннар дөньясы объектларын (яисә аерым төрләрне) куллануга чикләүләр һәм тыюлар кертү, ә шулай ук эпизоотия яки янгын куркынычы булган очракларда;<br>2. Гаризага экспертиза уздыру нәтиҗәләре буенча, фәнни оешмаларның компетентлы кире йомгагы;<br>3. Элек бирелгән рөхсәтнамә буенча, хайваннар дөньясы объектларын тоту турында | Тәртип п.2.9 |

| | | |
|---|---|---|
| | отчет бирмәү;<br>4. Тапшырылган документларда дөрес булмаган мәгълүмат табу;<br>6. Гаризада күрсәтелгән таләпләрне бозу<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору нигезләре юк. | |
| 2.10. Дәүләт хезмәте күрсәткән өчен алына торган дәүләт пошлинасы яки башка төрле түләүнең тәртибе, күләме һәм алу нигезләре | Хайваннар дөньясы объектларын тотуга рөхсәтнамә бирү өчен, 650 сум дәүләт пошлинасы алына.<br>Квитанция үрнәге 3 нче кушымтада бирелгән | п.п. 96 п. 1 333.33 маддә РФ СК |
| 2.11. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә, түләүнең күләмен исәпләү методикасы турында мәгълүматны кертеп,дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури һәм мәҗбүри булып торучы алынучы түләүләрнең тәртибе, күләме һәм нигезләре. | Түләү алынмый. | |
| 2.12. Дәүләт хезмәтен күрсәтү турында гариза биргәндә һәм андый хезмәтләрне күрсәтүнең нәтиҗәсен алганда чират көтүнең максималь срогы | Гариза бирүченең кабул итүне көтү (кабул итү) вакыты 15 минуттан да артмаска тиеш.<br>Аерым дәрәҗәдәге дәүләт хезмәтен алучылар өчен чиратлылык билгеләнмәгән. | РФ Президентының 601 нче боерыгы |
| 2.13. Дәүләт хезмәтен күрсәтүне сорап | Гариза кергән көнне.<br>Электрон рәвештә, ял (бәйрәм) көнендә кергән | |

| | | |
|---|---|---|
| мөрәҗәгать итүченең гаризасын теркәү вакыты,шул санда электрон рәвештә | мөрәҗәгать, ял (бәйрәм) көненнән соң килгән эш көнендә теркәлә. | |
| 2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган бүлмәләргә карата таләпләр, шул санда күрсәтелгән объектлар, Россия Федерациясенең инвалидларны иҗтимагый яктан яклау турындагы кануны белән тәңгәл килеп, инвалидлар йөрерлек өчен җайлы булырга тиеш, шулай ук андый хезмәтне күрсәтү турында турыдан-туры күренә торган, текстлы һәм мультимедиа мәгълүмат белән җиһазландырылырга тиеш. | Дәүләт хезмәтен күрсәтү янгынга каршы һәм янгын сүндерү системасы белән,мәгълүмат стендлары белән,документларны тутыру өчен яраклы булган җиһазлар булган биналарда алып барыла.<br>Дәүләт хезмәтен күрсәтү урынына инвалидлар өчен җайлы керү-чыгу урыннары тәэмин ителә.<br>Дәүләт хезмәтен күрсәтү турында турыдан-туры күренә торган, текстлы һәм мультимедиа мәгълүмат инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен истә тотып җиһазландырылырга тиеш. | Боерык № 880 |
| 2.15. Дәүләт хезмәтеннән файдалана алу мөмкинлеге һәм сыйфат күрсәткечләре, шул санда дәүләт хезмәтен күрсәткәндә гариза бирүченең урындагы затлар белән аралашу саны һәм вакыты, дәүләт хезмәтен дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган, күпфункцияле үзәкләрдә алу мөмкинлеге, дәүләт хезмәтен дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган, күпфункцияле үзәкләрнең ераклашкан эш урыннарында алу мөмкинлеге, дәүләт хезмәтен алу барышы турында мәгълүмат | Дәүләт хезмәтеннән файдалана алу мөмкинлеге күрсәткечләре:<br>Комитет биналарының җәмәгать траспортына якын булу;<br>гаризалар кабул итәр өчен саны буенча җитәрлек белгечләр булу, шулай ук документлар кабул итәр өчен бина булу;<br>дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы мәгълүматның “Интернет” челтәре мәгълүмат ресурсларында, мәгълүмат стендларында, Комитетның рәсми сайтында булу;<br>гаризаны электрон рәвештә бирү мөмкинлеге | |

| | | |
|---|---|---|
| алу мөмкинлеге ,шул санда мәгълүмати-коммуникация технологияләрен кулланып | булу;<br>инвалидларга, башка затлар белән бертигез дәүләт хезмәтен алырга кымачаулый торган киртәләрне җиңеп чыгарга булышу;<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфат күрсәткечләре булып түбәндәгеләр тора<br>документларны кабул итү һәм карап тикшерү срокларын үтәү;<br>дәүләт хезмәте нәтиҗәсен алу срогын үтәү;<br>Комитет белгечләре тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтү барышында бу регламентны бозу турында нигезле шикаятьләр булмау;<br>гариза бирүченең Комитет белгечләре белән аралашу саны;<br>дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны шәхси тапшырганда - ике тапкырдан да артмаска тиеш (консультацияләрне санамыйча) ;<br>дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны почта аша яки электрон рәвештә тапшырганда – бердән дә артмаска тиеш.<br>Гариза бирүченең Комитет хезмәткәре белән кабул ителү вакыты 15 минуттан да артмаска тиеш.<br>Дәүләт хезмәтен күпфункцияле үзәкләрнең ераклашкан эш урыннарында алу мөмкинлеге юк.<br>Дәүләт хезмәтен алу турында мәгълүматны бәйге җиңүчесе Комитеттан шәхси барып ала. | |

| | | |
|---|---|---|
| | Дәүләт хезмәтен күрсәтү барышы турында мәгълүмат , гариза бирүче белән Комитетка шәхси барып алынырга мөмкин. | |
| 2.16. Дәүләт хезмәтен электрон формада күрсәтү үзенчәлекләре | Заявка может быть представлена (направлена) заявителем в виде электронного документа, подписанного усиленной квалифицированной электронной подписью, через информационно-телекоммуникационные сети общего доступа, в том числе через информационно-телекоммуникационную сеть «Интернет» и Портал государственных и муниципальных услуг Республики Татарстан. | 210-ФЗ номерлы Федераль канун, 63-ФЗ номерлы Федераль канун. |

**3. Административ процедураларның (гамәлләрнең) катнашмасы, эзлеклелеге һәм үтәлү сроклары, аларны үтәү тәртибенә таләпләр, шул санда административ процедураларны электрон рәвештә күрсәтү үзенчәлекләре, ә шулай ук административ процедураларны күпфункцияле үзәкләрдә, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торганкүпфункцияле үзәкләрнең ераклашкан эш урыннарында башкару үзенчәлекләре**

3.1. Дәүләт хезмәте күрсәткәндәге гамәлләрнең эзлеклелек тасвирламасы

3.1.1.Дәүләт хезмәтен күрсәтү үз эченә түбәндәгеләрне ала:

гариза бирүчене консультацияләү, шул санда гариза бирүчегә дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерүдә булышу.

гаризаны һәм документларны кабул итү һәм рәсмиләштерү;

дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы әгъзаларга, идарәара мөрәҗәгатьләрне әзерләү һәм юнәлтү;

рөхсәтнамәне яки кире кагу турында хатны әзерләү;

гариза бирүчегә рөхсәтнамәне яки кире кагу турында хатны тапшыру;

техник хатаны төзәтү;
күп функцияле үзәк аша, күп функцияле үзәкнең ераклашкан эш урыны аша дәүләт хезмәтен күрсәтү тәртибе.
3.1.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең блок-схемасы әлеге административ регламентның 5 нче кушымтасында бирелә.

3.2. Гариза бирүчене консультацияләү, шул санда гариза бирүчегә дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерүдә булышу.

Гариза бирүче, дәүләт хезмәтен алу тәртибе турында консультация алырга дип,шул санда гаризаны рәсмиләштерү өчен, телефоннан һәм (яки) электрон почта аша, Татарстан Республикасының рәсми порталындагы интернет-кабул итү бүлмәсе аша (http://ojm.tatarstan.ru.) һәм шәхси Комитетка мөрәҗәгать итәргә хокуклы.
Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен җаваплы Бүлек белгече, гариза бирүчегә консультация бирә, шул исәптән дәүләт хезмәте алу өчен мөрәҗәгать итү формасы һәм башка мәсьәләләр буенча, гаризаны рәсмиләштерергә булыша.

Процедура гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көнне үтәлә.

Процедура нәтиҗәсе: дәүләт хезмәтен алу сораулары буенча консультация, документларны тутыру өлешендә булышлык.

3.2. Гариза бирүчене консультацияләү, шул санда гариза бирүчегә дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерүдә булышу.

Гариза бирүче, дәүләт хезмәтен алу тәртибе турында консультация алырга

дип, телефоннан һәм (яки) электрон почта аша, һәм шәхси Бүлеккә мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен җаваплы Бүлек белгече, гариза бирүчегә консультация бирә, шул исәптән дәүләт хезмәте алу өчен мөрәҗәгать итү формасы һәм башка мәсьәләләр буенча, гаризаны рәсмиләштерергә булыша.

Бу бүлек белән билгеләнгән процедура гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көнне үтәлә.

Процедура нәтиҗәсе: дәүләт хезмәтен алу сораулары буенча консультация, документларны тутыру өлешендә булышлык.

3.3. Гаризаны кабул итү һәм теркәү

3.3.1. Гариза бирүче Комитетка шәхси, почта аша, электрон почта аша, Татарстан Республика Хөкүмәтенең Интернет-кабул итү бүлмәсе аша, дәүләт хезмәтен күрсәтү турында гариза белән мөрәҗәгать итә.

Гариза Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша бирелергә мөмкин.

3.3.2. Бүлек белгече:

гаризаны кабул итә һәм терки;

гариза бирүче хокуклы вәкил сыйфатында яки дәүләт хезмәтен алырга вәкаләтле зат сыйфатында килгән очракта, гариза бирүченең вәкаләтләрен тикшерә;

бу Регламентның 2.5. пунктында күрсәтелгән документларның булуын тикшерә;

гаризаны гариза бирүчегә шәхси тапшыра яки почта аша яки электрон почта аша ( гариза бирүченең теләге буенча), документларны кабул итү вакытын, теркәү номерын күрсәтеп, гаризаның күчермәсен җибәрә.

Бу пунктта билгеләнгән процедуралар гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көнне үтәлә.

Процедура нәтиҗәсе: дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен,кабул ителгән һәм теркәлгән документлар.

3.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы әгъзаларга, идарәара мөрәҗәгатьләрне әзерләү һәм юнәлтү.

3.4.1. Бүлек белгече электрон рәвештә идарәара электрон мөнәсәбәт системасы аша сораулар юнәлтә:

хайваннар дөньясы объектларын тотуга рөхсәтнамә бирү өчен дәүләт

пошлинасын түләүне раслау турында ;

юридик затларның Бердәм дәүләт реестрыннан яки шәхси эшмәкәрләрнең Бердәм дәүләт реестрыннан мәгълүматлар бирү турында.

Бу пунктта билгеләнгән процедуралар алдагы процедура тәмамланганнан соң, бер эш көнендә үтәлә.

Процедура нәтиҗәсе: Дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы әгъзаларга, идарәара мөрәҗәгатьләрне әзерләү һәм юнәлтү.

3.4.2. Мәгълүматларны бирүче белгечләр, идарәара электрон мөнәсәбәт системасы аша кергән сораулар нигезендә, сорала торган документларны (мәгълүматларны) тапшыралар яки дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларның( мәгълүматларның) булмавы турында белдерү юнәлтәләр.

Бу пункт белән билгеләнә торган процедуралар, документларны (мәгълүматларны) бирә торган оешмага, идарәара электрон мөнәсәбәт системасы аша мөрәҗәгать кергәннән соң, әгәр дә федераль кануннар, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең хокукый актлары һәм федераль кануннар белән тәңгәл килеп кабул ителгән Татарстан Республикасының норматив-хокукый атлары белән, идарәара мөрәҗәгатькә җавапны әзерләүгә һәм юнәлтүгә башка вакыт билгеләнмәсә, биш эш көне эчендә башкарыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: Комитетка җибәрелгән документлар яки кире кагу хаты.

3.5. Рөхсәтнамәне яки кире кагу турында хатны әзерләү;

3.5.1. Бүлек белгече:

документларны, бу регламентның 2.5. пунктына туры килүенә тикшерә;

Бүлек белгече гариза бирүчедән һәм дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы әгъзалардан кергән документлар нигезендә:

Рөхсәтнамә бланкын тутыра яки Рөхсәтнамәне бирмәү турында хат әзерли;

тутырылган Рөхсәтнамә бланкын яки Рөхсәтнамәне бирмәү турында хатны Бүлек башлыгына раштыруга җибәрә.

Бу пунктта билгеләнгән процедуралар, Регламент белән каралган, алдагы процедура тәмамланганнан соң, бер эш көнендә үтәлә.

Процедуралар нәтиҗәсе: Бүлек башлыгына раштыруга җибәрелгән тутырылган Рөхсәтнамә бланкы яки Рөхсәтнамәне бирмәү турында хат.

3.5.2. Бүлек башлыгы Рөхсәтнамә бланкын яки Рөхсәтнамәне бирмәү турында хатны раштыра һәм аларны Комитет рәисенә җибәрә.

Бу пунктта билгеләнгән процедуралар, Регламент белән каралган, алдагы процедура тәмамланганнан соң, бер эш көнендә үтәлә.

Процедура нәтиҗәсе: Комитет рәисенә җибәрелгән Рөхсәтнамә бланкы яки Рөхсәтнамәне бирмәү турында хат.

3.5.3. Комитет рәисе Рөхсәтнамәгә яки Рөхсәтнамәне бирмәү турында хатка имза куя һәм аны кире Бүлеккә юнәлтә.

Бу пунктта билгеләнгән процедуралар, Регламент белән каралган, алдагы процедура тәмамланганнан соң, бер эш көнендә үтәлә.

Процедура нәтиҗәсе: имза куелган Рөхсәтнамә яки Рөхсәтнамәне бирмәү турында хат.

3.6. Рөхсәтнамәне яки Рөхсәтнамәне бирмәү турында хатны тыпшыру.

3.6.1. Бүлек белгече Рөхсәтнамәне яки Рөхсәтнамәне бирмәү турында хатны рәсмиләштерә һәм гариза бирүчегә хат юнәлтә.

Бу пунктта билгеләнгән процедура, Комитет рәисе белән Рөхсәтнамәгә яки Рөхсәтнамәне бирмәү турында хатка имза куйган көнне үтәлә.

Процедура нәтиҗәсе: рәсмиләштерелгән Рөхсәтнамә яки Рөхсәтнамәне бирмәү турында хат.

3.6.2. Бүлек белгече гариза бирүчегә яки аның вәкаләтле затына (ышанычнамә булган очракта), имза астына Рөхсәтнамәне тапшыра.

Бу пунктта билгеләнгән процедура, Рөхсәтнамәгә яки Рөхсәтнамәне бирмәү турында хатка имза куйган көнне үтәлә.

Процедура нәтиҗәсе: гариза бирүчегә тапшырылган Рөхсәтнамә.

3.7. Техник хатаны төзәтү ( хәреф хатасы яки арифметик хата):

Өземтәне яңадан төзү, элек бирелгән рөхсәтнамәдә җибәрелгән, техник хатаны төзәтү (хәреф хатасы яки арифметик хата) белән бәйле рәвештә үтәлә.

Рөхсәтнамәне яңадан ясау, техник хатаны төзәтү турында теркәлгән гариза (гаризаның формасы бу регламентның 6нчы кушамтасында бирелде) һәм аңа кушылган хаталы рөхсәтнамә нигезендә үтәлә.

3.7.1. Бүлек белгече:

- гаризаны кабул итә һәм терки;

- гариза бирүчегә,документларны кабул итү вакытын һәм бирелгән номеры күрсәтеп, гаризаның күчермәсен тапшыра яки почта яки электрон почта аша( аның теләве буенча) юнәлтә.

Бу пункт белән урнаштырыла торган процедуралар, гариза теркәлгән көнне башкарылалар.

Процедура нәтиҗәсе: кабул ителгән һәм теркәлгән гариза

3.7.2. Бүлек белгече:

- рөхсәтнамәне яңадан ясый;

- рөхсәтнамәне яңадан ясау турында гариза бирүчегә хат проектын әзерли һәм килештерү өчен Бүлек башлыгына юнәлтә.

Бу пункт белән урнаштырыла торган процедуралар, гариза Бүлек белгеченә җибәрелгәннән соң, бер эш көне эчендә башкарылалар.

Процедура нәтиҗәсе: Бүлек башлыгына юнәлтелгән өземтә.

3.7.3. Бүлек белгече әзерләнгән Рөхсәтнамәнең дөреслеген тикшерә, хат проектын яраштыра һәм аларны Комитет рәисенә юнәлтә.

Бу пункт белән урнаштырыла торган процедура, Бүлек башлыгына яраштырырга юнәлтелгән Рөхсәтнамә һәм хат проекты кергән көнне башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: Комитет рәисенә яраштырырга юнәлтелгән Рөхсәтнамә һәм хат проекты.

3.7.4. Комитет рәисе хат проектын һәм аңа куелган Рөхсәтнамәгә кул куя һәм Бүлеккә юнәлтә.

Бу пункт белән урнаштырыла торган процедура, Бүлек башлыгыннан хат проекты кергән көнне башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: яраштырылган хат проекты һәм Рөхсәтнамә.

3.7.5. Бүлек белгече, Комитет рәисе белән кул куелган, дәүләт хезмәтен күрсәтү турындагы хатны рәсмиләштерә, һәм Рөхсәтнамә белән бергә гариза бирүчегә яки аның вәкаләтле затына(ышанычнамә булса) имза астына тапшыра.

Бу пункт белән урнаштырыла торган процедура, гариза бирүче яки аның вәкаләтле заты килгәннән соң, бер эш көне эчендә башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: гариза бирүчегә бирелгән хат һәм техник хаталары төзәтелгән Рөхсәтнамә.

3.8 Күп функцияле үзәк аша дәүләт хезмәтен күрсәтү тәртибе, КПҮ ераклашкан эш урыны.

Дәүләт хезмәте ( шул санда дәүләт хезмәтен күрсәтүгә гаризаны тапшыру) күп функцияле үзәк, КПҮ ераклашкан эш урыны аша күрсәтелми.

## 4. Административ регламентны үтәү артыннан тикшерү формалары

4.1. Дәүләт хезмәтен күрсәтү барышында, җаваплы затлар белән, бу регламентның кагыйдәләрен һәм башка норматив-хокукый актларны тотуны һәм саклауны, ә шулай ук җаваплы затлар белән карарлар кабул итүне тикшерү Бүлек башлыгы белән үткәрелә.

Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатын тикшерү, тикшерүләр уздыруны, урындагы затлары гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаятьле гариза бирүчеләр мөрәҗәгатьләрен карау, алар буенча карар кабул итүне һәм җавап әзерләүне үз эченә ала.

Административ процедураларны үтәүне саклау артыннан тикшерү рәвешләре:

эш башкаруны алып бару;

каралган документларның нәтиҗәсе бу регламентның таләпләренә туры килүе;

документларны кабул итү вакытын һәм тәртибен саклау;

дәүләт хезмәтен күрсәткәндә, аның нәтиҗәсен бирү вакытын һәм тәртибен саклау.

Тикшерүләрне уздыруның кабатлануы планлы (эш планнары нигезендә башкарыла) һәм планнан тыш ( гариза бирүченең мөрәҗәгате буенча) характер йөртә.

4.2. Тикшерүләрне уздыру нәтиҗәләре буенча, гариза бирүчеләрнең хокуклары бозылу ачыклаган очракта, дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен җаваплы вазыйфаи затлар, Россия Федерациясе кануннары белән каралган тәртиптә җаваплылыкка тарттырылалар.

4.3. Гариза бирүчеләр ягыннан дәүләт хезмәтен күрсәтү артыннан тикшерү.

Гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтелүне контрольдә тоту дәүләт хезмәтен күрсәткәндә Дәүләт комитетының ачык эшчәнлегендә, дәүләт хезмәтен күрсәтү тәртибе турында тулы, актуаль һәм дөрес мәгълүмат алганда һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү процессында мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) судка кадәр карау мөмкинлегендә гамәлгә ашырыла.

## 5. Комитетның, ә шулай ук аның вазыйфаи затларының һәм дәүләт хезмәткәрләренең карарлары һәм кылган (кылмаган) гамәлләренә шикаять белдерүнең судка кадәр (судтан тыш) тәртибе

5.1. Дәүләт хезмәтен алучылар Комитетның, Комитетның вазыйфаи затларының һәм Комитетның дәүләт хезмәткәрләренең гамәлләрен (гамьсезлеген)

судка кадәрге тәртиптә Комитетка шикаять кылу хокукына ия. Комитет рәисе белән кабул ителгән карарларга шикаять Татарстан Республикасының Министрлар Кабинетына бирелә.

Гариза бирүче түбәндәге очракларда шикаять белән мөрәҗәгать итә ала:

1. дәүләт хезмәтен күрсәтү турындагы гаризаны теркәү срогы бозылу;
2. дәүләт хезмәтен күрсәтү срогы бозылу;
3. дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен, гариза бирүчедән Россия Федерациясе норматив-хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив-хокукый актларында күздә тотылмаган документлар таләп итү;
4. гариза бирүчедән, дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен, Россия Федерациясе норматив-хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив-хокукый актларында күздә тотылган документларны кабул итүдән баш тарту;
5. нигезләре федераль законнар һәм аларга туры китереп кабул ителгән Россия Федерациясенең норматив-хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив-хокукый актларында күздә тотылмаган булса , дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту;
6. дәүләт хезмәтен күрсәткәндә, гариза бирүчедән Россия Федерациясенең норматив-хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив-хокукый актларында күздә тотылмаган түләү таләп итү;
7. Комитетның, аның вазыйфаи затының дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән ялгыш язуларны һәм хаталарны төзәтүдән баш тартуы яки андый төзәтүләр өчен билгеләнгән срокның бозылуы;
8. дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәләре буенча документларны тапшыру вакыты яки тәртибе бозылу;
9. нигезләре федераль кануннар һәм аларга туры китереп кабул ителгән Россия Федерациясенең норматив-хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив-хокукый актларында күздә тотылмаган булса, дәүләт яки муниципаль хезмәтне күрсәтүне туктатып тору.

5.2. Шикаять почта аша, яки “Интернет” челтәрен кулланып, электрон почта аша(e-mail:ojm.tatar.ru), Комитетның рәсми сайтына, Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең бердәм порталы, Татарстан Республикасының Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша, күп функцияле үзәк аша, ә шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә тапшырыла ала.

5.3. Дәүләт хезмәтен алучыларның шикаяте түбәндәгеләрне үз эченә алырга тиеш:

1) гамәлләренә (гамьсезлегенә) шикаять бирелә торган, Комитетның, Комитетның вазыйфаи затларының яки дәүләт хезмәткәрләренең исеме;

2) гариза бирүче-физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы булган очракта), яшәгән урыны турында белешмәләр, гариза бирүче –юридик затның урнашкан урыны турында белешмәләр, һәм шулай ук гаризачыга җавап бирү өчен элемтә телефонының номеры (номерлары), (булган очракта) электрон

почта һәм почта адресы (адреслары);

3) Комитетның, аның вазыйфаи затының яки дәүләт хезмәткәренең шикаять кылына торган карарлары һәм гамәлләре (гамьсезлекләре) турында белешмәләр;

4) Комитетның, аның вазыйфаи затының яки дәүләт хезмәткәренең карарлары һәм гамәлләре (гамьсезлекләре) белән килешмәве буенча гаризачы тарафыннан китерелгән дәлилләр.

5.4. Шикаятьне карау вакыты – аны теркәүдән соң 15 эш көне эчендә. Дәүләт хезмәтен күрсәтүче Комитет, аның вазыйфаи заты гариза бирүчедән документларны кабул итүдә яки ясалган хаталарны төзәтүдә яки андый төзәтүләрне ясау срогы бозылу очрагында кире кагуга шикаять биргән очракта – аны теркәгәннән соң биш эш көне эчендә.

5.5. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча, түбәндәге карарларның берсе кабул итәлә:

шикаять, шул исәптән кабул ителгән карарны кире кагу, җибәрелгән хаталарны төзәтү, дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документлардагы хаталарны һәм җитешсезлекләрне төзәтү, аларны алу Россия Федерациясенең норматив-хокукый актлары, Татарстан Республикасының норматив-хокукый актлары, әлеге Регламент белән каралмаган акча чараларын гаризачыга кайтарып бирү формасында, һәм шулай ук бүтән формаларда канәгатьләндерелә;

шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тарту.

Регламентның бу пунктында күрсәтелгән, карарны кабул иткән көннән соң килүче көннән дә соңга калмыйча гаризачыга язмача формада һәм гаризачының ихтыяры белән электрон формада шикаятьне карау буенча мотивлаштырылган җавап юнәлтелә.

5.6. Шикаятьне карау барышында яки нәтиҗәсендә административ хокук бозылу яисә җинаять кылу билгеләре ачыкланса, шикаятьне карау вәкаләтләре белән вәкаләтләнгән вазыйфаи заты кичекмәстән бар булган материалларны прокуратура әгъзаларына юнәлтә.

Татарстан Республикасы территориясендә аучылык һәм биологик су ресурсларына кертелмәгән , хайваннар дөньясы объектларын тотуга рөхсәтнамәләр бирү буенча дәүләт хезмәтен күрсәтүнең Административ регламентына
1нче кушымта.

Форма

______________________________________________________________

(Татарстан Республикасы башкарма хакимият әгъзасының исеме, адресы)

Аучылык һәм биологик су байлыкларына кертелмәгән, хайваннар дөньясы объектларын тотуга **Рөхсәтнамә №** _______

Бирелде : ____________________________________________________________

(оешманың, шәхси эшмәкәрнең исеме)

Тотарга рөхсәт итеқә: ___________________________________________________

(фамилия, исем, атасының исеме)

Киләсе төрдәге хайваннар дөньясы объектларын атуга: ______________________
______________________________________________________________________

Табу урыны: __________________________________________________________

Табу вакыты: _______________________________________________________

Табылган продукция: ___________________________________________________

Рөхсәтнамәне башка затларга бирү тыела.
Рөхсәтнамә гамәлдән чыккач, аны куллану турында отчет белән 10 көн эчендә кире кайтарырга кирәк.

Бирү вакыты: __________________

Рәис: ____________ ____________

Татарстан Республикасы территориясендә аучылык һәм биологик су ресурсларына кертелмәгән , хайваннар дөньясы объектларын тотуга рөхсәтнамәләр бирү буенча дәүләт хезмәтен күрсәтүнең Административ регламентына 2 нче кушымта.

Гаризаның тәкдим ителгән формасы (ТР МК 22.04.2010 елдан 293 номерлы карары белән расланган)

Татарстан республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты рәисенә

___________________________________

(Ф.И.О.)

**Татарстан Республикасы территориясендә аучылык һәм биологик су байлыкларына кертелмәгән , хайваннар дөньясы объектларын тотуга**

**гариза**

Гариза бирүче турында мәгълүмат: __________________________________________________________

(юридик затлар өчен – оешманың тулы исеме,

_______________________________________________________________________________________

банк реквизитлары, адрес, телефон; для физик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр өчен-

_______________________________________________________________________________________

фамилия, исем, атасының исеме,

_______________________________________________________________________________________

паспорт мәгълүматлары, адрес, телефон)

Хайваннар дөньясы объектларын тоту максаты: _________________________________________________

Хайваннар дөньясы объектларын тоту вакыты: _________________________________________________

Тотарга планнаштырылган хайваннар дөньясы объектларының исемлеге: _________________________

Тотыла торган хайваннар дөньясы объектларын саны (төр буенча): ______________________________

Хайваннар дөньясы объектларының яшь катнашмасы (билгеләп булган очракта): ________________

Хайваннар дөньясы объектларын тоту территориясе (акваториясе): ________________________________

Хайваннар дөньясы объектларын тоту ысулы: ___________________________________________________

Хайванлар дөньясы объектларын тоту коралы: ________________________________________

Тота торган хайваннар дөньясы объектларының яшәү шартлары: ________________________

Рөхсәтнамәне куллану өчен җаваплы зат:: _____________________________________________

(исем, фамилия, атасының исеме)

Хайваннар дөньясы объектларын тотуда катнашучы затлар исемлеге:

_____________________________________________________________________________

(исем, фамилия, атасының исеме)

Шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә риза.

__________________________________ _________________________________________

(гариза бирүченең имзасы) (гариза бирүченең фамилиясе һәм инициаллары)

Дата: "___"______ 20___

Татарстан Республикасы территориясендә аучылык һәм биологик су ресурсларына кертелмәгән , хайваннар дөньясы объектларын тотуга рөхсәтнамәләр бирү буенча дәүләт хезмәтен күрсәтүнең Административ регламентына 3 нче кушымта.

**Извещение**

*Форма № ПД-4сб (налог)*

УФК по РТ (Государственный комитет Республики Татарстан по биологическим ресурсам) КПП **165501001**

(наименование получателя платежа)

**1660111252** | | **92701000**

ИНН налогового органа* | и его сокращенное наименование | (Код ОКТМО)

**40101810800000010001** в Отделение-НБ Республика Татарстан г. Казань

(номер счета получателя платежа) | (наименование банка)

БИК: 049205001 Кор./сч.:

Прочие государственные пошлины за совершение прочих юридически значимых действий **04810807240011000110**

(наименование платежа) | (код бюджетной классификации КБК)

Плательщик (Ф. И. О.) ____

Адрес ____

ИНН ____ № л/с ____

Сумма 650 руб. 00 коп. Статус 13

**Плательщик (подпись)** ____ Дата: ____ ____ 20__ г.

** или иной государственный орган исполнительной власти*

**Кассир**

---

УФК по РТ (Государственный комитет Республики Татарстан по биологическим ресурсам) КПП **165501001**

(наименование получателя платежа)

**1660111252** | | **92701000**

ИНН налогового органа* | и его сокращенное наименование | (Код ОКТМО)

**40101810800000010001** в Отделение-НБ Республика Татарстан г. Казань

(номер счета получателя платежа) | (наименование банка)

БИК 049205001 Кор./сч. ____

Прочие государственные пошлины за совершение прочих юридически значимых действий **04810807240011000110**

(наименование платежа) | (код бюджетной классификации КБК)

Плательщик (Ф. И. О.) ____

Адрес ____

ИНН ____ № л/с ____

Сумма 650 руб 00 коп. Статус 13

**Плательщик (подпись)** ____ Дата: ____ ____ 20__ г.

** или иной государственный орган исполнительной власти*

**Квитанция**

**Кассир**

Татарстан Республикасы территориясендә аучылык һәм биологик су ресурсларына кертелмәгән, хайваннар дөньясы объектларын тотуга рөхсәтнамәләр бирү буенча дәүләт хезмәтен күрсәтүнең Административ регламентына
4 нче кушымта.

**Аучылык һәм биологик су байлыкларына кертелмәгән, хайваннар дөньясы объектларын тотуга рөхсәтнамәләр бирү буенча дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен җаваплы вазыйфаи затларның һәм әгъзаларның реквизитлары**

**Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты**

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Комитет рәисе | 211-66-94 | Fjodor.Batkov@tatar.ru |
| Бүлек башлыгы | 211-70-78 | Ilfat.Valeev@tatar.ru |
| Бүлек белгечләре | 211-70-78 | Anna.Mironova@tatar.ru |
| | | Mariya.Ushakova@tatar.ru |
| | | Roza.Minnegulova@tatar.ru |

**Татарстан Республикасының Министрлар Кабинеты Аппараты**

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Җир асты байлыкларын, табигый байлыкларны куллану һәм тирә якны саклау сораулары буенча бүлек башлыгы | 264-77-78 | Marat.Fashutdinov@tatar.ru |
| Татарстан Республикасының Министрлар Кабинеты Аппаратының экология һәм табигатьне куллану бүлегенең баш киңәшчесе | 264-76-35 | Olga.Kasatkina@tatar.ru |
| Татарстан Республикасының Министрлар Кабинеты Аппаратының экология һәм табигатьне куллану бүлегенең баш киңәшчесе | 264-76-35 | Ekaterina.Filinova@tatar.ru |

Татарстан Республикасы территория-сендә аучылык һәм биологик су ресурсларына кертелмәгән, хайваннар дөньясы объектларын тотуга рөхсәтна-мәләр бирү буенча дәүләт хезмәтен күрсәтүнең Административ регламентына 5 нче кушымта.

**Татарстан Республикасы территория-сендә аучылык һәм биологик су ресурсларына кертелмәгән, хайваннар дөньясы объектларын тотуга рөхсәтна-мәләр бирү буенча дәүләт хезмәтен күрсәткәндә эш тәртибенең блок-схемасы**

Гариза бирүче Комитетка дәүләт хезмәтен алу тәртибе турында консультация алырга дип,шәхси яки телефоннан һәм (яки) электрон почта аша мөрәҗәгать итә.

↓

Бүлек белгече гариза бирүчегә консультация бирә, шул исәптән дәүләт хезмәте алу өчен мөрәҗәгать итү формасы һәм башка мәсьәләләр буенча.
(гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көнне)

↓

Гариза бирүче, дәүләт хезмәтен алыр өчен, документларны Комитетка тапшыра

↓

Бүлек белгече, дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итә һәм терки
(гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көнне)

↓

Бүлек белгече, дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы әгъзаларга, идарәара мөрәҗәгатьләрне әзерли һәм юнәлтә. (1 көн)

↓

Дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы әгъзалардан, сорала торган документларны (мәгълү-матларны) алу яки документларның( мәгълүматларнын) булмавы турында белдерү алу
(5 эш көне)

↓

Бүлек белгече документларны, бу регламентның 2.5. пунктына туры килүен тикшерә.

↓

Бүлек белгече Рөхсәтнамә бланкын яки Рөхсәтнамәне бирмәү турында хатны тутыра һәм раштыруга Бүлек башлыгына юнәлтә. (1 көн)

↓

Бүлек башлыгы Рөхсәтнамә бланкын яки Рөхсәтнамәне бирмәү турында хатны раштыра һәм аларны Комитет рәисенә җибәрә. (1 көн)

↓

Комитет рәисе Рөхсәтнамәгә яки Рөхсәтнамәне бирмәү турында хатка имза куя һәм аны кире Бүлеккә юнәлтә. (1 көн)

↓

Бүлек белгече Рөхсәтнамәне яки Рөхсәтнамәне бирмәү турында хатны рәсмиләштерә һәм гариза бирүчегә хат юнәлтә. (алда килгән процедураны үтәгән көндә)

↓

Бүлек белгече гариза бирүчегә яки аның вәкаләтле затына, имза астына Рөхсәтнамәне тапшыра.
(алда килгән процедураны үтәгән көндә)

Татарстан Республикасы территориясендә аучылык һәм биологик су ресурсларына кертелмәгән, хайваннар дөньясы объектларын тотуга рөхсәтнамәләр бирү буенча дәүләт хезмәтен күрсәтүнең Административ регламентына 6 нчы кушымта.

Татарстан Республикасының
Биологик ресурслар буенча
дәүләт комитеты рәисенә

_______________________________
(Ф.И.О.)

_______________________________
(физик затлар өчен: Ф.И.О.,
адрес (почта һәм(яки)электрон)

_______________________________
Юридик затлар өчен: оешманың исеме,
адрес (почта һәм(яки)электрон)

**Техник хатаны төзәтү турында гариза.**

Дәүләт хезмәте нәтиҗәсе булып килгән документны төзегәндә җибәрелгән хата турында хәбәр итәм.

___________________________________________________________________________
(бирелгән документ)

_________________________________________________________________күрсәтелгән.

Дөрес мәгълүматлар:
___________________________________________________________________________.

Дәүләт хезмәте нәтиҗәсе булып килгән документны төзегәндә җибәрелгән техник хатаны төзәтүегезне һәм ул үзгәрешләрне документка кертүегезне сорыйм.
Киләсе документларны терким:

1. ______________________________________________________________

2.______________________________________________________________

Яңадан төзелгән килешүнамәнең әзерлеге турында хәбәр итүегезне сорыйм.
___________________________________________________________________________
(шәхси яки адресны күрсәтеп, почта аша)

"___"__________ 20___ ел. ________________________________________
(гариза бирүченең имзасы) (имзаны чишү)